ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# «Тоткарланган транспорт чараларын махсуслаштырылган урынга күчерү, аларны саклау, кире кайтару, күчергән һәм саклаган өчен чыгымнарны түләү тәртибе турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2019 елның 25 сентябрендә
кабул ителде

## 1 статья

«Тоткарланган транспорт чараларын махсуслаштырылган урынга күчерү, аларны саклау, кире кайтару, күчергән һәм саклаган өчен чыгымнарны түләү тәртибе турында» 2012 елның 17 маендагы 24-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2012, № 5 (I өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 44 (I өлеш), аңа түбәндәге эчтәлекле $2^1$ статья өстәп, үзгәреш кертергә:

«$2^1$ статья. **Тоткарланган транспорт чараларын махсуслаштырылган урынга күчерүне, аларны саклауны, кире кайтаруны, күчергән һәм саклаган өчен чыгымнар түләүне оештыру**

Тоткарланган транспорт чараларын махсуслаштырылган урынга күчерүне, аларны саклауны һәм хуҗаларына, хуҗалары вәкилләренә яисә үзендә әлеге транспорт чараларын йөртү өчен кирәкле документлары булган затларга кире кайтаруны, транспорт чараларын тоткарлау алымын куллануга китергән административ хокук бозулар өчен административ җаваплылыкка тартылган затларның тоткарланган транспорт чараларын күчергән һәм саклаган өчен түләвен оештыру Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексы нигезендә Татарстан Республикасының тиешле функцияләр йөкләнгән махсуслаштырылган дәүләт бюджет учреждениесе тарафыннан гамәлгә ашырыла.».

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ * АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Казан, Кремль
2019 ел, 26 сентябрь
№ 68-ТРЗ